ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
СӘМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

“16” октябрь 2023 ел Сәмәкәй авылы № 36

**“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлегенең Сәет авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары. “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында " 21.09.2022 ел, №647 Россия Федерациясе Президенты Указы белән, Тукай муниципаль районы “Сәмәкәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлегенең Сәет авылында 2023 елнын 28 октяберендә 10.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Сәмәкәй авыл җирлегенең Сәет авылы территориясендә 2024 елда балигъ булган, Сәмәкәй авыл җирлегенең Сәет авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, аларнын суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- Бөек Ватан сугышы һәйкәле территориясен төзекләндерү, материаллар сатып алу, конструкцияләрне ремонтлау һәм урнаштыру;

хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме

“ӘЙЕ” “ЮК”.

2.1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган Сәмәкәй авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнарны һәм гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә.

3. Татарстан Республикасы, Тукай районы, Сәет авылы, Сәүдә урамы, 37 нчы йорт адресы буенча гражданнар җыенын үткәрергә.
4. Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны авыл җирлегенен мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
7. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Сәмәкәй авыл җирлеге Башлыгы

Совет Рәисе И. М. Усманов